Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Иске Каразерик 1 нче санлы балалар бакчасы «Аккош»

# ПРОЕКТ

## **“Милли тэрбия”**

Эшлэде:
1 нче категорияле тэрбияче
Каюмова Л.А.

**Балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын проектлаштыру**

Милли үзаң төшенчәсенең эчтәлеге: **“Милләтләрнең милләт буларак яшәешен тәэмин итүче, башка милләтләр арасында эреп юкка чыгудан саклаучы күәтле тойгыдыр”**

Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында , бар булганны балаларыбызга җиткерү ─ һәрберебезнең төп вазифасы. Күңелендә милләтенә тугрылыкхисе булган кеше моңа битараф кала алмый торгандыр. Ана теле - сабыйларга аң-белем һәм тәрбия бирү өчен иң файдалы чишмә.

21 гасыр да милли хисләр тәрбияләү проблемасы аеруча актуальләште. Яңа заманда радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, тәрбиясенә әдәпсезлекне сеңдергән заманда, милләтнең ничәмә- ничә еллар буе туплаган тәҗрибәсе, әхлак кагыйдәләре югала чыгып бара. Менә шуның өчен дә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларга халкыбыз хәзинәләре нигезендә милли үзаң тәрбияләүгә аеруча зур мәгънәгә ия булырга тиеш.

Шул уңайдан без үзебезнең Иске Каразирек авылы 1 санлы “Аккош” балалар бакчасында Лэпбук аеруча актуаль кулланабыз. Милли үзаңны үстерү максатларын гамәлгә ашыру өчен, педагогик эшне дөрес итеп, фәнни нигездә оештыру, белем-тәрбиянең әһәмиялелеген, метод һәм чараларын төгәл итеп билгеләү сорала.

Лэпбук: "Милли киемнәр» һәм «Киемнәр дә безне бизиләр" проектлары буенча «Әбиемнең серле сандыгы»

З.м. Зарипова, Л. Н. Вәкилованың "Туган телдә сөйләшәбез" программасы буенча "Лэпбук" авторлык эшләнмәсе"

Лэпбук уенының максаты: балаларны татар теленә өйрәтү буенча укыту-методик комплекты белән каралган лексик минимумны режим моментларында һәм уен эшчәнлегендә беркетү.

Төп сүзләр: укыту, татар теле, ФГОС ДО, уен, лэпбук.

Актуальлек Мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә кертү белән бәйле рәвештә, һәр педагог үз педагогик эшчәнлегендә яңа алымнар, идеяләр эзли. Укыту һәм тәрбияне тулы белем бирү процессына берләштереп, лэпбук педагогка һәр баланың шәхси үзенчәлекләренә нигезләнеп эшчәнлек алып бару, баланың үз белемен сайлауда актив катнашучы шартлар тудыру мөмкинлеге бирә. Лэпбукны куллану, яшәү урынына, җенесенә, милләтенә, теленә, социаль статусына, шул исәптән махсус белем бирү ихтыяҗлары булган балалар өчен бик файдалы алым.

Л. с. Выготский, а. м. Шахнарович, А. А. Леонтьев, а. ш. Әсәдуллин, Ф. ф. харисов, ч. М. тикшеренүләрендә дә теге яки бу телне максатчан өйрәнү кирәклеге ассызыклана. Алар, нәкъ менә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның телләргә өйрәтүдә иң яхшы чор булуын, чөнки ул тел мәгълүматын үзләштерүгә эмоциональ әзерлек һәм истә калдыруның ныклыгы белән характерлана.

Бу уеннар балаларны ике дәүләт теленә өйрәтүнең конкрет бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән, ләкин шул ук вакытта аларда тәрбияви һәм уен эшчәнлегенә тәэсир итә.

Кызганычка каршы, теоретик базаның җитәрлек дәрәҗәдә булмавы тәрбия эшен катлауландыра. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда милли үзаң тәрбияләү буенча аеруча мөһим эш үткәрү зарурлыгы һәм теоретик базаның булмавы каршылык тудыра.

Бу каршылык тикшеренү проблемасын билгеләргә ярдәм итә: хәзерге заман шартларында мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән шушы юнәлешләрдә эшне ничек нәтиҗәле һәм максатчан итеп оештырырга була?

Тикшеренү максаты: мәктәпкәчә яшьтәге балаларның дусларына, туганнарына, төрле милләт халкына булган ихтирам ролен теоретик нигезләрдә һәм экспериментал рәвештә тикшереп карарга.

Тикшеренү объекты: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда милли үзаң тәрбияләү процессы.

Тикшеренү предметы: милли үзаң тәрбияләү вакытында төрле эш формаларын куллану.

Тикшеренү гипотезасы: милли үзаң тәрбияләү аерым бер шартларны тормышка ашырганда уңышлы булачак:

- тәрбия эше мәктәпкәчә яшьтәге балаларның төрле милләт халкына мәхәббәт тәрбияләү төшенчәсе эчтәлеген исәпкә алганда тормышка аша;

- эш формалары эчтәлекле һәм кызыксындыручан итеп сайлаган очракта;

- әби-бабаларыбызның үткән тормышы белән таныштыру этаплап алып барылса;

Максаттан һәм гипотезадан чыгып, түбәндәге бурычларны куйдык:

- тикшеренү проблемасы буенча педагогик, методик әдәбиятны өйрәнү, алдынгы эш тәҗрибәсе белән танышу һәм анализлау;

- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гуманлы хисләр тәрбияләү үзенчәлекләрен билгеләү;

- милли үзаң тәрбияләү күрсәткечләрен һәм дәрәҗәләрен ачыклау;(Татар милли ашлары)

- эксперименталь рәвештә туган телгә мәхәббәт тәрбияләү методикасын тикшереп карау.

Тикшеренүнең методологик һәм теоретик нигезләре Туган җир, туган тел, туган табигать һәм аның данлы шәхесләренә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү мөмкинлеге һәм зарурлыгы турында фәнни хезмәткәрләрнең карашлары.

Куелган бурычларны чишү өчен безгә ярдәмгә Лэпбук килә. Тикшеренү методлары:

- өйрәнелә торган проблема буенча педагогик әдәбиятны теоретик анализлау;

- педагогик эксперимент (констатация, формалаштыручы, контроль этаплар);

- балалар эшчәнлеген күзәтү; ( “Дөрес итеп милли киемнәрне җый”)
- эшчәнлек продуктларын өйрәнү;
- тәрбиячеләр белән эш алып бару;(Милли киемнәр турында сөйлә)
- әти-әниләр белән эш;(татар халык иҗатын бергәләп өйрәнү)
- балалар белән эш;(“Курчакны киендер”)
- кызыксындыручан оешмалар белән эш.(Бизәкне дөрес сайла)

Тикшеренү эшенең фәнни яңалыгы түбәндәгечә:

а) мәктәпкәчә чорда туган телгә мәхәббәт тәрбияләү;

б) балаларның төрле милләт халкына булган мөнәсәбәтләрен билгеләү;

в) милли җанлы шәхес сыйфаты буларак үз милләтенә һәм башка милләт халкына булган карашларын формалаштыруны теоретик нигезләү һәм эксперименталь тикшерү.

Яклауга түбәндәге положенияләр чыга:

1. Милли үзаң тәрбияләү мөмкинлеге һәм кирәклеге.
2. Мәктәпкәчә чор – патриотик хисләр, шул исәптән халыклар арасында дуслык тәрбияләү өчен иң сензетив период булып санала. Шушы чорда иң әһәмиятле әхлакый сыйфатлар формалаша.
3. Милли үзаң тәрбияләү максаты белән мәктәпкәчә учреждениеләрдә төрле эш формалары куллану.

**Балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын проектлаштыруда өлкән тәрбияче роле**

- Методик әсбаплар булдыру
- Милли проект буенча балалар бакчасы концепциясендә аерым бүлек булдыру
- Милли тәрбия бирү эшен еллык планда чагылдыру
- Иҗади төркем белән куелган максатны тормышка ашыру буенча системалы эш алып бару
- Төрле оешмалар белән эш планы төзегәндә дә милли тәрбиягә игътибар бирү

- Проблема буенча методик берләшмәләрдә чыгыш ясау
- Яшь белгечләр белән тиешле дәрәҗәдә эшләү
- Күргәзмәләр, конкурслар оештыру
- Милли үзәкләр булдыру

**Балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын проектлаштыруда тәрбиячеләр белән оештырылган эшләр**

- Педагогик киңәшмәләр
- Мини конференцияләр
- Семинар-практикумнар
- Сәнгатьле укулар, консультацияләр
- Бөек шәхесләр белән очрашу
- Милли мәгарифне үстерү буенча перспектив планнар төзү, методик киңәшләр эшкәртмәсе булдыру, ачык шөгыльләр, методик берләшмәләр, бәйге-конкурслар оештыру
- Үз белемен үстерү эшен камилләштерү, югары дәрәҗәдәге тәҗрибәләр белән уртаклашу

**Балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын проектлаштыруда балалар белән оештырыла торган эшләр**

- шөгыльләр;
- әңгәмәләр;
- музыкаль әдәби кичәләр, викториналар;
- өлкәннәр белән очрашулар;
- бәйрәм иртәләре;
- әти-әниләр белән берлектә төрле мавыктыргыч ярышлар, бәйгеләр;
- күңел ачулар;
- тематик кичәләр;
- максатлы сәяхәтләр;
- күргәзмәләр;
- конкурслар;

- жыелышлар һ.б.

Сабый чактан ук бала ана телен ишетә, әкиятләр аңа дөнья тәрәзәсен ачалар, балачакны эмоциональ яктан бизиләр, ягымлылык, өмет, ышаныч уяталар. Әкиятләр балаларны дулкынландыра, мавыктыра, көлдерә, елата. Һәрхалыкның үз әкиятләре бар, алар барысы да буыннан буынга әхлакый кыйммәтләрне тапшыралар.

Балаларны туган халкыбызның үткәне, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, гаилә шәҗәрәсе, йолалары һәм бүгенге тормыш белән таныштыру зарур.

Халык җәүһәрләрен балалар җиңел, табигый кабул итәләр. Аларда юмор да бар, ямансулык та, бер-береңә, иптәшләреңә, үз туганнарыңа һәм ниһаять иң мөһиме төрле милләт халкына тирән мәхәббәт ята.

**Балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын проектлаштыруда эти-әниләр белән оештырыла торган эшләр**

- Традициягә кергән һәм кермәгән алымнар кулланып төркем белән һәм гомуми жыелышлар үткәрү
- Төрле ситуатив мәсьәләләр чишү
- төрле мавыктыргыч ярышлар, бәйгеләр
- күңел ачулар;
- тематик кичәләр;
- музыкаль әдәби кичәләр, викториналар;

**Балалар бакчасында милли тәрбия бирү системасын проектлаштыруда җәмәгатьчелек белән эш**

- мәктәпләр белән эш
- китапханәләр
- педагогик уку йорты
- музейларга сәяхәт
- ишек алды клублары

Нәтиҗә:

Балаларны балалар бакчасында татар теленә өйрәтү-хәзерге дөньяда иң актуаль проблемаларның берсе.Аралашу чарасы буларак татар телен яхшы белү-бүгенге көннең төп максаты: ул киләчәктә уңышлы уку өчен генә түгел, ә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның интеллектуаль һәм әхлакый үсеше өчен дә кирәк. Шушы  уңайдан Лэпбук-икенче дәүләт теленә өйрәтүнең төп чарасы булып тора.